КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 август г.Казань № 691

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2025 елларга Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыеннарында кергән мәсьәләләрне хәл итү буенча чаралар комплексын («юл картасын») раслау турында» 2020 ел, 20 апрель, 309 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2025 елларга Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыеннарында кергән мәсьәләләрне хәл итү буенча чаралар комплексын («юл картасын») раслау турында» 2020 ел, 20 апрель, 309 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 9 май, 373 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыеннарында һәм «Минем депутат» онлайн-сервисы һәм «Мобиль кабул итү» проекты аша VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау кампаниясе барышында кабул ителгән мәсьәләләрне хәл итү буенча чаралар комплексын («юл картасын») раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Декарарга теркәлгән 2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыеннарында һәм «Минем депутат» онлайн-сервисы һәм «Мобиль кабул итү» проекты аша VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау кампаниясе барышында кабул

ителгән мәсьәләләрне хәл итү буенча чаралар комплексын («юл картасын») расларга.»;

Әлеге карар белән расланган 2020 – 2025 елларга Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыеннарында кергән мәсьәләләрне хәл итү буенча чаралар комплексын («юл картасын») яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин